ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.09.2017 с. Кильдеево 5

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 12.06.2002 елдан №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Килди авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Килди авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын түбәндәге сорау буенча чыгарырга:

«2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юллауга ризалыгыгыз бармы:

- Килди авылы Үзәк урамында 250 метр озынлыктагы зиратка керү капкасына кадәр, 2 су үткәргеч торбалар куеп, вак таш җәелгән җирле әһәмияттәге юл төзелеше.

- Уланово авылы, Заозерная урамында зират ягына 1 су үткәргеч торба куелган вак таш өслекле җирле әһәмияттәге юллар салу.

- Харино авылы Нагорная урамында су башнясы ягына вак таш җәелгән җирле әһәмияттәге юллар салу.

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин